КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 8 июль г.Казань № 536

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегияне раслау турында» 2021 ел, 24 декабрь, 1285 нче карары белән расланган 2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегиягә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегияне раслау турында» 2021 ел, 24 декабрь, 1285 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 27 декабрь, 1422 нче, 2023 ел, 20 март, 286 нчы, 2023 ел, 17 июль, 840 нчы, 2023 ел, 21 август, 995 нче, 2024 ел, 19 апрель, 264 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегиягә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекнең 2.4 бүлекчәсенең дүртенче абзацында «алар буйсынуындагы учреждениеләр,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил,» сүзләрен өстәргә, «адвокатлар» сүзеннән соң «һәм нотариуслар» сүзләрен өстәргә;

III бүлекнең 3.3 бүлекчәсендә:

икенче абзацта «2019 – 2025 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «(хәзерге вакытта килешү 2022 елга кадәр имзаланды)» сүзләрен төшереп калдырырга;

IV бүлекнең 4.3 бүлекчәсендә:

уналтынчы абзацта «2021 елда бирелергә» сүзләрен «2024 елда бирелергә» сүзләренә алмаштырырга, «2020 ел һәм 2021 елда» сүзләрен «2023 ел һәм 2024 елда» сүзләренә алмаштырырга;

унҗиденче абзацта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

унсигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

V бүлектә:

5.2 бүлекчәдә:

сигезенче абзацта «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту» ярдәмче программасы кергән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту» дәүләт программасы» сүзләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту» дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «Ярдәмче программа кысаларында» сүзләрен «Программа кысаларында» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 бүлекчәнең унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә республика башкарма хакимият органнары алдында торган бурычларны хәл итү «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасында каралган чараларны гамәлгә ашыру юлы белән тәэмин ителә.»;

VI бүлекнең 6.3 бүлекчәсенең алтынчы абзацында «Программа бурычлары буенча» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программасы бурычлары киселешендә» сүзләренә алмаштырырга, «2013 - 2023 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

VII бүлектә:

7.1 бүлекчәдә:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган 2014 - 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» сүзләренә алмаштырырга;

7.3 бүлекчәнең егерменче абзацында «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасы һәм «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә күрсәтелә торган дәүләт хезмәте була» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Стратегиягә кушымтада:

2.5 пунктның «граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек һәм СО НКОга ярдәм итү, чит ил гражданнарын (мигрантларны) җайлаштыруга һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән проектларны гамәлгә ашыруга субсидияләр рәвешендә грантлар бирү» юлын төшереп калдырырга;

2.6 пунктның 3 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында гамәлгә ашыру»;

4.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «4.10. | Яшьләрнең һөнәр сайлауга теләктәшлеген, мәнфәгатьләрен, һәвәслекләрен исәпкә алып, шулай ук хезмәт базары ихтыяҗларына туры китереп, | эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре тарафыннан эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәри белем алу һәм яшьләргә өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарның һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениеләре (килешү буенча) | эшсезләр составында 16 - 29 яшьлек яшьләр өлеше, процент |
| | | эшчеләр һөнәрләре буенча яшьләр һәм студентлар хезмәт отрядларында катнашучыларның һөнәри әзерлеге | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениеләре (килешү буенча) | әлеге хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән студент хезмәт отрядларында катнашучылар санына карата укырга җибәрелгән студент хезмәт отрядларында катнашучылар саны, процент». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин